ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Әлки муниципаль районы
Чиябаш авыл җирлеге
Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Совет Шибашинского сельского поселения
Алькеевского муниципального района

422886, ТР, Рус Чиябаш авылы,
Тынычлык урамы, 20 й.
Факс (84346) 75-4-37

422886, РТ, Алькеевский район,
с. Русские Шибаши, ул.Мира, д.20
Факс (84346) 75-4-37

**РЕШЕНИЕ** **Рус Чиябаш авылы** **КАРАР**

2018 елның 14 апреле 7№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру (кабул итү) турында килешү төзү тәртибе хакында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге Уставы нигезендә Чиябаш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру (кабул итү) турында килешү төзү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

Чиябаш авыл җирлеге башлыгы: И.З.Сәмигуллин

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Чиябаш авыл җирлеге Советының
2018 елның 14 апрелендәге
7 номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру (кабул итү) турында килешү төзү тәртибе

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чиябаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру (кабул итү) турында килешү төзү тәртибе 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Чиябаш авыл җирлеге Уставы нигезендә төзелгән һәм Чиябаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба - Авыл бирлеге) үз эшчәнлеген җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне әзерләгәндә, биргәндә (кабул иткәндә) тапшырганда һәм гамәлгә ашырганда үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган кагыйдәләрне (алга таба - Килешү) билгели.

1.2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары Әлки муниципаль районының (алга таба - Район) җирле үзидарә органнары белән Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә район бюджетына җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына үз вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы. Бу очракта Районның җирле үзидарә органнары 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, районның муниципаль хокукый актлары, җирлекнең муниципаль хокукый актлары, Килешү нигезендә җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

1.3. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Район бюджетыннан Авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә аларның бер өлешен кабул итү турында, җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә хокуклы.

Бу очракта Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, районның муниципаль хокукый актлары, җирлекнең муниципаль хокукый актлары, Килешү нигезендә районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

### 2. Килешүләр төзү буенча җирле үзидарә органнары компетенциясе

2.1. Авыл җирлеге советы:

1) Килешүләр төзү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибен раслый;

2) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү, (тапшыру) турында карар кабул итә

3) төзелгән килешүләрнең үтәлешен тикшереп тора.

2.2. Авыл җирлеге башкарма комитеты:

1) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) инициативасы белән чыга;

2) килешүләр төзи;

3) тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар өлешенең күләмен билгеләү тәртибен билгели;

4) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны исәпләп чыгара;

5) әгәр Килешүдә башкасы каралмаган булса, җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган (кабул ителгән) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар кабул итә;

6) төзелгән Килешүләр шартларын үти.

## 3. Килешү төзү турында инициатива тәкъдим итү

3.1. Авыл җирлеге башкарма комитеты Килешүне төзү турындагы инициативаны күрсәтергә хокуклы.

3.2. Чираттагы финанс елына Килешү төзү турындагы инициативаны күрсәтү Авыл җирлеге Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру (кабул итү) турында Авыл җирлегенең башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдимен җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән тәкъдимнәр Авыл җирлеге Советы тарафыннан бер айдан да артык булмаган вакытта каралырга тиеш.

3.3. Килешүләр чираттагы финанс елына Авыл җирлеге бюджеты турындагы карар проектын керткәнче төзелергә тиеш.

## 4. Килешү проектын әзерләү

4.1. Муниципаль Авыл җирлегенең һәм Районның җирле үзидарә органнары Килешү проектын әзерләү өчен уртак вакытлы комиссия, эшче төркем төзергә мөмкин.

4.2. Килешү проекты язма рәвештә рәсмиләштерелә. Килешү төзелгәнче (тиешле яклар белән имзаланганчы) Килешү проекты Авыл җирлеге һәм Районның тиешле органнарында (структур бүлекчәләрендә) хокукый һәм финанс-икътисадый экспертиза узарга тиеш.

4.3. Әгәр Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары белән Район җирле үзидарә органнары арасында Килешү проектының барлык шартлары буенча килешүгә ирешелсә, Килешү проекты әзерләнгән дип санала.

## 5. Килешү шартлары

5.1. Килешүне әзерләгәндә, караганда һәм төзегәндә түбәндәге шартлар билгеләнә:

1) Килешү исеме, аны төзү датасы һәм урыны;

2) Килешү якларының (Килешү төзелә торган җирле үзидарә органнарының) исеме, Килешү төзелә торган норматив хокукый актларның исеме;

3) Килешү предметы;

4) тапшырыла торган вәкаләтләрнең составы (исемлеге);

5) тапшырылучы вәкаләтләрнең бер өлешен башкарганда Килешү якларының хокуклары һәм бурычлары (Килешүнең һәр ягы хокуклары һәм бурычлары күрсәтелә);

6) Килешү төзү вакытына бюджетара трансфертлар күләмендә тапшырыла торган вәкаләтләрне як тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү;

7) тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен тапшырыла торган мөлкәт исемлеге, әлеге мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе (тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен мөлкәтне тапшыру таләп ителсә, мөлкәтне тапшыру һәм куллану тәртибе һәм шартлары күрсәтелә);

8) тиешле җирле үзидарә органнарының алар тарафыннан тапшырыла торган вәкаләтләрне үтәү турында хисап бирү тәртибе (хисаплылыкның төрләре, рәвешләре һәм сроклары күрсәтелә);

9) Килешү шартларының яклар тарафыннан гамәлгә ашырылуын тикшереп тору тәртибе (контроль тәртибе һәм формалары күрсәтелә);

10) Килешү шартларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы (Килешүне үтәмәгән өчен җаваплылык төрләре һәм барлыкка килү нигезләре, финанс санкцияләре күрсәтелә);

11) Килешүне үтәү барышында яклар тарафыннан бәхәсләрне карау тәртибе;

12) Килешү төзелә торган вакыт һәм аның үз көченә керү датасы;

13) Килешүне үзгәртү һәм өзү, шул исәптән килешүне вакытыннан алда туктату яисә аның аерым нигезләмәләрен, шулай ук килешүне үзгәртү һәм өзү нәтиҗәләре һәм тәртибе;

14) Йомгаклау нигезләмәләре (Килешү һәм Килешүнең башка нигезләмәләре ничә нөсхәдә төзелгән);

15) Килешү якларының имзалары.

5.2. Килешүнең мөһим шартлары булып тора:

1) Килешү төзелә торган билгеле бер вакыт;

2) гамәлләрне, шул исәптән вакытыннан алда, туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләр;

3) тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар өлешенең күләмен билгеләү тәртибе;

Килешүне үтәмәгән өчен финанс санкцияләре.

## 6. Килешүләр төзү тәртибе

6.1. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары белән килешү төзүе Советның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү (тапшыру) турындагы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.2.Җирле үзидарә органнарының Килешүгә кул куюга вәкаләтле вазыйфаи затлары Килешүне үзләре имзалый.

6.3. Килешү, әгәр ул язма рәвештә рәсмиләштерелгән, вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан имзаланган һәм Килешү якларының мөһерләре белән беркетелгән булса, төзелгән дип санала.

6.4.Төзелгән килешүләрне исәпкә алу, теркәү һәм саклауны "Чиябаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 7. Килешүгә үзгәрешләр кертү

Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Яклар тарафыннан әлеге Тәртип нигезендә өстәмә Килешүне имзалау юлы белән гамәлгә ашырыла.